


ЧАЯН

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ* ФЕВРАЛЬ * 2016 КАЗАН

4



Сергей АНДРИАНОВ

АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

Обама белән Путин арасында телефон аша сөйләшү үткәрелгән. Америка президенты, аңа кирәргә ярамый дип белдерүләр язылган Мәскәүдәге ларекларны җимерүне сораган.

Пенсионерларга, светофорның кызыл уты янганда да урам аша чыгарга рөхсәт булачагын белдергән закон проекты карала. Алдан исәпләп караганда, бюджетка берничә миллиард сум экономия килеп чыгачагы күздә тотыла.

Лабуда-үзәк сораштырулары буенча, россиялеләрнең 90% ы, алдагы Госдумага сайлауларда "Бердәм Россия" җиңәчәк, дип исәпли. Ләкин алар үзләре тавыш бирергә җыенмыйлар.

Дин әһелләре эволюция тәгълиматының һәм Зур шартлауның барлыгын танысалар да, үзләренең "Ходай тарафыннан барлыкка килүләренә" һич тә шикләнмиләр.

Банкир П. бер үк вакытта ике урында – Канарда һәм федераль эзләнүдә булу сыйфатына ия.

Лондон мэры велосипедта хатынын законсыз ташуда фаш ителә.

Сугару министры, смартфоны күлгә төшү сәбәпле, күлне киптергән.

Астрономнар ун ел буе микроволновка сигналларын тоту белән шөгыльләнгәннәр. Алар моны космостан килгән хәбәрләр түгел микән дип шикләнгәннәр.

Бер ир, машина урлап качуы турында сорау алу түгел микән дип, соңга калмас өчен тагын машина урлаган.

Әни кеше, улын армиягә алсыннар өчен, военкомат хезмәткәренә ришвәт биргән. Хәзер аңа миллион сум штраф түләү куркынычы яный.

Америка полициясе үзен-үзе үтерүчегә ярдәмгә ашыга һәм, гадәттәгечә, аны атып үтерә.

Акчага кискен мохтаҗлык кичерү сәбәпле, бер хатын, күкрәген зурайту өчен кредит алган.

Судья хулиганга төрмә белән өйләнүнең кайсысын булса да сайлап алу хокукы биргән.

Авыру эт, үзе белеп, ветеринарга барган, ә песи, горурлыгын җиңеп, хастаханәдә ятучы хуҗабикәсенең хәлен белергә килгән.

Сантехник, табиб булган булып, айлар буе гинекология бүлегендә йөргән.

Кечкенә кыз, үзен Супермен дип күрсәткән каракны бишенче этаждан сикерергә мәҗбүр иткән.

Илдар НӘФИЕВ






ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Чит илдән кертелгән продуктларның бәясе күтәрелүне әле аңларга була. Алар долларга бәйләнгән. Тик безнең товарларга да бәяләр үсә бит! Мәсәлән, күптән түгел бер җирле җитештерүченең «100% табигый экологик чиста атлан мае» кыйммәтләнде. Бу нинди хәл инде?

Л. ГАФУРОВА

БАЛЫК БИСТӘСЕ

– Чөнки нефть һәм пальма маена акцизларны күтәрделәр, – диде Шомбай ага.



Эрнест ДЫШАЕВ





Сак булыгыз! Ишегалдында усал эт, өстенә баса күрмәгез!

Целлюлитсыз күмәчләр.

Москвич 412 автомобиле сатам йә Nokia 5130 телефонына алыштырам.

Сезнең ишегалдында баз сатып алам.

Циркка тагын 10 гимнаст кирәк.

Эш өчен кеше эзлибез. Түләү акчалата.

Игътибар! Шикле әйбер күрсәгез, шикле чырай күрсәтегез.

(белдерүләр)

Вячеслав БИБИШЕВ



ХОКУКСЫЗ ХОКУК

Барыгызның да исендәдер: демократик үзгәрешләр башында Гайдар һәм аның командасы шәхси милек изге, кагылгысыз нәрсә дип тәкрарлыйлар иде. Гадәттәгечә, алдыйлар иде, әлбәттә... Мондый либераль әфсеннәр олигархларга һәм хакимияткә генә кагылышлы иде. Гади халык, үзенең фәкыйрь милкенә хуҗа булгач та, реформа давылларында хокуксыз тузан булып кына калды...

Казанның Отар бистәсендә кырык җир биләмәсе хуҗалары, анда төзелгән йортлары белән, көтмәгәндә үзләренең законсыз зат булулары турында хәбәрдар булалар. Центральная, Гагарин, Калинин һәм Идел буе урамнарында яшәүчеләр очраклы рәвештә аларның «изге шәхси милке» – йортлар, гаражлар һәм бакчаларның шәһәр төзү планына кертелмәгәнлеге хакында беләләр. Бу хәбәрне биләмәсендә оныклары өчен йорт төзергә булган Гөлшат Мөхәммәтова җиткерә.

Рөхсәт алу максаты белән ул Казанның архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә мөрәҗәгать итә. Җавап һич тә көтелмәгән булып чыга: аның җир биләмәсе «Д 2 зонасы»на керә икән. Ә анда 1998 елдан шәхси торак төзү тыелган. Кибетләр, күңел ачу үзәкләре, офислар төзергә телисең икән – рәхим ит! Ә оныклар өчен йорт төзү турында – уйлама да!

Бу яңалык Гөлшат апа өчен өстенә салкын су койгандай була. Дару кабып, документларын җыеп, ул регистрация палатасына чаба.

– Ничек болай килеп чыга соң? – дип сорый ул. – Җиргә һәм ничәмә-ничә буын үскән нәни өйгә милек хокукын өч ел элек теркәдем. Әгәр җир минеке икән, нигә мин анда тагын бер йорт салып куя алмыйм?

Регистрация палатасында җилкәләрен җыералар: аларга җирдән файдалану тәртибенең үзгәрүе турында бернинди информация кергәне юк.

Шуннан Гөлшат апа өчен бюрократия киртәләре белән көрәш башлана. Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгында аның мәсьәләсе белән шөгыльләнергә теләмиләр: җирле органнарга мөрәҗәгать итегез! Казан Башкарма комитетыннан аны авыл Советына, ә аннан – Архитектура идарәсенә җибәрәләр.

Нигә бу үзгәрешләр турында бистәдә яшәүчеләргә бернәрсә дә әйтмәделәр дигән сорауга кыска җавап бирелә: моны беркем дә эшләргә тиеш түгел, яшәүчеләр үзләре кызыксынырга тиеш.

Борчуга төшкән бистә кешеләренең тырышлыклары белән зоналар картасына үзгәрешләр кертү хокукы булган махсус комиссия төзелә. Ләкин бу әле үзгәрешләр кертеләчәк дигән сүз түгел. Ул әле ярты елдан соң гына җыелачак, ә «мәсьәләне өйрәнү» бик озакка сузылырга мөмкин. Өстәвенә, кирәкле документлар исемлегендә «махсус органнарның өстәмә йомгаклау документлары таләп ителергә мөмкин» дигән пункт бар. Ә бер йөк өстәмә кәгазьләр җыюның нәрсә икәнен безнең халык яхшы белә...

Бу вакыйганың нәрсә белән бетәсе әлегә билгеле түгел, ләкин бер нәрсә ачык: мыштым гына уздырылган «операция» нәтиҗәсендә дистәләгән гаиләләр хокуксыз булып калды. Аларның ата-бабалары төзегән йортларының бульдозер астында калуы, ә алар урынына кибетләр һәм офислар калкып чыгуы мөмкин. Ә милеккә хуҗа булу турындагы таныклыклар буш кәгазь кисәге булып чыкты...

Людмила САФИУЛЛИНА

ТИШЕК КОПЧӘК

Сергей ТЮНИН



КӨТЕЛМӘГӘН ЧИШЕЛЕШ


Машинасөючеләр шаярта: каршы яктагы юл һәрвакыт әйбәтрәк. Бәлки, менә шушы шаяртуга ышангандыр машина йөртүче бер күркәм ханым Казан Кремле янындагы юлның каршы полосасыннан барганда. Видеодан караганда ул бер дә исе китмичә бара да бара, аңа кычкырталар, ә ул "колагына да элми". Әлбәттә, бу хәл шәһәр кешеләренең ачуын бик кабарта. Ләкин, шулай булуга карамастан, машина йөртүче чибәркәйне яклап, Россиянең Татарстан буенча машинасөючеләр федерациясе җитәкчесе Рамил Хәйруллин чыга. Аның фикере буенча, әлеге кыз... берни дә бозмаган, чөнки әлеге юлда билгеләмәләр дә, борылыш ясарга ярамаган күрсәткечләр дә юк. Аңлатып булмаслык очракны Транспорт министрлыгы да таныган. Үзләренең стандарт җавап бирү язмасы урынына: "Юл билгеләре акча табу мәсьәләсен хәл иткәннән соң куелачак", – диелгән. Мәсьәлә тиз ара чишелеш таба, һәм "Кирпеч" шул ук көнне куела.

Алмаз КӘРИМОВ

Виталий ФЕОКТИСТОВ



Ринат БӘШИРОВ



Александр КОСМЫЛИН





• • •

Ир кеше сатучыдан сорый:

– Әйтегез әле, сездә боксер перчаткалары бармы?

– Юк.

– Ә йөзү өчен башлык?

– Анысы да юк.

– Тимераяк?

– Бу бит аракы, шәраб сата торган бүлек.

– Ярый, алайса миңа бер шешә акны бирегез әле.

Сатучы аракыга дип китә. Әлеге ир, уйланып, үз-үзенә:

– Ходай күреп тора, югыйсә чынчынлап спорт белән шөгыльләнәсем килгән иде бит!

• • •

– Сезгә операция ясадылармы инде? – дип сорый табиб.

– Әйе.

– Ну, ничек?

– Өч мең тәңкәгә.

– Сезнең белән нәрсә булды дип сорамакчы булам?

– Бер генә мең.

– Сез һаман аңламыйсыз. Нәрсәгә зарланасыз дип соравым минем.

– Артык кыйбат түләтәсез.

• • •

– Бабакай, әйтегез әле, озак яшәвегезнең сере нәрсәдә?

– Күмәргә акча булмауда...

• • •

– Доктор, сәламәтлекне акчага сатып алып булмый, дип дөрес әйтәләрме?

– Кайлардан табасыз сез андый ахмак фикерләрне, күгәрченем? Акча булса, без сезгә авыртуны теләсә ничек уйлап чыгарабыз.

• • •

– Кичә мине эт тешләде.

– Котырганмы?

– Юк, әйбәт эт. Котырганы булса, мин аның койрыгыннан тартып маташаммы инде!

• • •

– Доктор, ирем бик каты авырый. Кайвакытта мин аңа сәгатьләр буе әллә ниләр сөйлим, ә ул мин әйткәннәрнең берсен дә ишетмәгән булып чыга.

– Бу – авыру түгел, ә Аллаһы Тәгаләнең бүләге!

ХӘРБИЛӘРНЕҢ – ХӘРБИЧӘ...

Александр БУЛАТОВ



ДЕМБЕЛЬ АЛЬБОМЫННАН

Солдатның башы уйлар өчен, ә мие фикер йөртү өчен.

Армиядә бөтен нәрсә дә бертөрле: кыркылган, буялган, ком сибелгән.

Әгәр дә сержантка ни дә булса әйтергә телисең икән, авызыңны томала.

Солдатның йөзе кайгы һәм уйчанлык чагылдырырга тиеш.

Солдат одеялындагы һәрбер бөрмә – дошман өчен юл!



Валерий ТАРАСЕНКО

МАХСУС ЧЫБЫК

Җитмешенче еллар ахырында безнең хәрби частька яңа командир җибәрделәр. Часть буенча йөреп чыкты да бу, бик канәгатьсез калды. Бөтен җирдә тәртипсезлек, хәтта койма да юк, территория буйлап җирле халык һәм аларның терлекләре йөри. Шунда ук полкны пехотага каршы махсус тимер чыбык белән әйләндереп алырга приказ бирелде. Белгән кешеләр ул чыбыкта хәтта БТР да буталып кала, дип сөйләделәр. Төнге караңгыда приказ үтәлде...

Таңда безне кычкырып сүгенү тавышы һәм сыерлар мөгрәве уятты. Чыбыкка казармалар яныннан фермага йөрергә ияләнгән савымчылар, ике “самовольщик” һәм ике сыер буталган иде. Аларны ирекккә чыгарырга ярты көн китте. Чыбыкны алып ташларга туры килде. Командир, каяндыр такта юнәтеп, безгә агач койма ясарга приказ бирде...

Р. ХАЛИТОВ

ӘЛМӘТ

УҢЫШ САКЛАУ

Болганчык туксанынчы еллар башында миңа Байкал буенда прапорщик булып хезмәт итәргә туры килде. Күрше авылда бер ялгыз карчык йортында – аерым бүлмәдә яшәдем. Берзаман әбекәй миңа зарлана: “тимурчылар” бакчасыннан ике куак бәрәңгесен казып алганнар. Бу – “разведка” булгандыр, бөтенләй бәрәңгесез калмаска иде ди...

Уйлап карадым да, бакчада сигнал минасы куярга булдым. Ул нәрсә кеше өчен куркыныч түгел, тик шартлаганда коточкыч итеп сызгыра һәм өскә фейерверкка охшаган сигнал ракеталары атып җибәрә. Урынын сайлап, “растяжка” куйдым да, төнге дежурствога киттем.

Иртән кайтып керүемә хуҗабикәм шат кыяфәт белән йөри. “Бакчада хәлләр ничек?” – дип сорыйм.

Ә ул:

– Әйбәт кенә: ике яңа чиләк, дүрт капчык һәм көрәк таптым...

Л. ИСМАЕВ

ӘГЕРҖЕ

ТӨП КОРАЛ

Безнең замполит майор Загорулько, политхезмәткәрнең төп коралы – сүз, дип кабатларга ярата иде. Бөтен частьне көлдергән аның кайбер “сүз”ләрен мин әлегә кадәр хәтерлим:

– һәм бу самовольщиклар авызыбызга капмадык та дигән булалар! Ә үзләренең борыннары кыпкызыл, кыяр кебек...

– Кичке аштан соң тыныч кына кызыл почмакта утырыгыз, “Красная звезда” укыгыз, телевизор карагыз... Тик ялгамагыз!


– “Ярыймы”, нинди сүз ул? Җанашыңны ботыннан тотарга ярый! Ә армиядә – “рөхсәт итегез!”

– Кем анда җыелышта ярты сырты белән борылып утыра?

– Солдат үз иркендә калган икән, шунда ук аның башында әшәке уйлар барлыкка килә!

Б. КРИВЦОВ

ТҮБӘН КАМА



Александр АЛЁШИН



Антон МАКУНИ



Мәңгелек хәрәкәт машинасы

Мин күптән түгел мәңгелек хәрәкәт машинасы уйлап чыгардым. Импортный миксер белән иттарткычтан. Аларның миксеры хәрәкәт өчен җавап бирә, ә безнең иттарткыч – мәңгелек өчен.

Дәүләт, әлбәттә, мондый уйлап табуга югары бәя бирәчәк, дип уйладым мин, һәм «Уйлап табулар комитетына» киттем. Кердем, карыйм – «Иванов А. А. – эксперт» дип язылган ишек. Шакыйм, Иванов янына керәм, шундый-шундый нәрсә – халык хуҗалыгы өчен һәм көндәлек тормыш өчен бик кирәкле әйбер, дим.

Иванов миңа сәерсенеп карады да:

Бу миңа түгел, бу Петровка, – ди.

Петров янына киттем. Ул мине тыңлады да:

– Бу миңа түгел, Сидоровка, – ди.

Сидоров янына кердем, ә ул миңа:

– Сезгә Иванов янына керергә кирәк, – ди.

Тагын Иванов янына киттем.

– Мин сезгә әйттем бит инде! Сезгә Петров янына керергә кирәк!

Шулай итеп кичкә кадәр йөгереп йөрдем: Иванов – Петров – Сидоров, Иванов – Петров – Сидоров.

Көн ахырында гына минем мәңгелек хәрәкәт машинасының аларга кирәк булмаганын аңладым. Алар аны үзләре уйлап чыгарганнар. Минекеннән күпкә яхшырагын...

Урамга чыгып, машинамны чүп савытына ташладым да өйгә кайтып киттем. Мәңгелек тормоз уйлап чыгарырга. Менә ул безнең илдә иң кирәкле әйбер булачак!

Фирдәвес ЗАРИФ

КЕМ ТАРАКАН САТА?

Илне инфляция зәхмәте сукканда Нуриның фатирын таракан басты. Ниләр генә кыланып карамады ул: төрле агулар дисеңме, кытай карандашлары... Тик берсе дә ярдәм итмәде. Тегеләр, доллар кебек, аста бер-ике көн тынып торалар да, тагын өскә күтәреләләр.

Өметен өздем дигәндә генә "бәхетсезлек килмәгән булса, бәхетем булмас иде" дигәндәй, башына бер фикер килде. Халыкта "сиңа таш белән атсалар, син аш белән ат!" дигән мәкаль бар бит. Америка безне санкцияләр белән тончыктырмакчы була, ә миңа ник шул тараканнарны эшкә җигеп файдаланмаска, ягъни үзләрендәге кебек таракан чабышлары уздырып карамаска! Миңа да шәп, тараканнар да үзләрен "Кеше!" итеп сизәрләр, кирәклекләренә сөенерләр! Һәм ул эшкә кереште. Фатирының киңрәк бүлмәсе уртасына зур өстәл әмәлләде. Өстәл читенә таракан оялары урнаштырды. Тараканнарның иң шәпләрен сайлады ул. Шуннан соң чат саен "Таракан ярышлары уздырам. Тараканнар нәселле, Америкадан кайтарылган" дигән (ялган булса да) белдерүләр ябыштырып чыкты.

Илләр арасындагы нормаль багланышлар сыман сату-алу, экспорт-импорт дигәндәй, гөрләп китте Нуриның. Зуррак тараканнарны ун доллардан сата, кечерәкләрен сигездән бирә. Тараканнарны прокатка да алырга мөмкин, кредитка да. Күмәртәм сатып алучыларга ташламалар да каралган. Тамаша кылучылар исә бер доллар исәбеннән түли. Инде хәлләнеп тә килә: машина сатып алды, яңа фатирга акча җыя Нури.

"Ашка таракан төште" дигәндәй, Нури кебек бүтән акыллы башлар да бу коммерция белән шөгыльләнә башлады. Җитмәсә, берсе, Нуриның бизнес буенча якын дусты, аның бик тә көчле, һәрвакыт җиңү яулаучы тараканын, ялгышып дигән булып, ярыш вакытында өстәлдән бәреп төшерде. Чемпион шундук җан тәслим кылды. Нуриның эшләре кыйтыкланды. Бизнесы сүнде, Нури бөлде.

Хәзер ул яңадан белдерүләр ябыштырып йөри: "Америка тараканнары урынына үзебезнекеләр дә бик әйбәт – импортозамещение!"

ЙОЛДЫЗ

ШИК

Типсә тимер өзәрлек
Өрлек шикелле егет
Күңелдә өмет уятмый.
Астан гына карап бара.
Уенда этлек кебек.


Иңенә сумка аскан,
Сакал мыек та баскан.
Террорчыдыр, мөгаен. –
Куркыныч уй телә мине
Шундыйны күргән саен.

Мин дә озын күлмәк кигән,
Итәге җиргә тигән.
Ап-ак яулык башымда.
Миннән дә шикләнәләрдер
Утырганнар каршымда.

Нинди көнгә килеп җиттек,
Кеше кешедән курка.
Көлсәң – көл еласаң – ела.
Әллә без акылдан яздык,
Әллә дөнья дивана?!



Валентин ДУБИНИН


Виктор ФЁДОРОВ







ПЕДАГОГЛАР ӨЧЕН ШПАРГАЛКА

Күптән түгел Татарстан укытучылары үзләрен мәктәп укучылары итеп тоярга мәҗбүр булдылар. Аларга профессиональ белем буенча тест узарга туры килде. Монда кайбер районнарның педагоглары гадәттән тыш югары нәтиҗәләр күрсәткән. Мондый хәлгә шатланасы гына югыйсә. Ләкин республиканың мәгариф министры Энгель Фәттаховны бу киресенчә, сагайткан. Укучылар бит ЕГЭны укытучыларына караганда күпкә начаррак биргәннәр. Педагоглар шпаргалка белән файдаланганнармы, әллә бай белемнәре белән балалар белән бүлешә белмәгәннәрме – бу турыда сүз министрлыкның коллегиясендә барачак.

ГРИППТАН КАЙДА КАЧАРГА

Россия призывникларына ниһаять рәсми рәвештә «качып ятарга» киңәш иттеләр. Дөрес, армиядән түгел, ә дуңгыз кизүеннән. Оборона министрлыгының баш санитар табибы Игорь Азаров әйтүенчә, грипп эпидемиясеннән иң яхшы качу урыны – коралλы көчләр сафында икән. Яшь солдатлар өстеннән даими күзәтү, каты режим һәм саф һавада булу авырумы-юкмы икәнен ачыкларга ярдәм итә. Шул ук вакытта санитар табиб чираттагы призывның яз көне, эпидемия узгач кына булуы турында нигәдер бер сүз дә әйтмәде.

ЯҢА ЫСУЛ

Белоруссиядә ниһаять җитәкче кадрларны тәрбияләүнең иң үтемле ысулын тапканнар. Илнең элеккеге Генераль прокурор урынбасары Александр Архипов, коррупция белән бәйле җинаятьләр өчен зонада тиешле срокның яртысын уздырганнан соң, гафу ителгән, һәм президент Лукашенко тарафыннан артта калган колхозны күтәрергә җибәрелгән. Ике ел элек мондый үсеш юлын МАЗның хәзерге генераль директоры Александр Боровский да үткән булган. Элекке «зек»ларның эш нәтиҗәләреннән бик канәгать булган Лукашенко бөтен җитәкчеләрне дә наралар аша уздырырга дигән тәкъдим белән чыккан. Батька, мөгаен, шаяртгандыр. Ләкин бу тәҗрибәгә игътибар итү зыянлы булмас иде.



“Чаян” күнекмәсе

ЙӨЗ УТЫЗ ДҮРТЕНЧЕ ТУР



Бу рәсемгә карагач, башка әллә нинди уйлар килә. Машинаң йөрми торган хәлгә килгәч: **“Ичмасам, ат та юк бит тарттырырга”,** – дип әйтеп куйган чаклар була. Ә боларның эшләре мөшкелрәк – ат эштән чыккан, арган. Авыл урамыннан, кеше көнләштереп, җилдереп кайтмак булганнардыр да бит, күрәсез, килеп чыкмаган... Хәер, бу минем бер караштан туган фикер генә, ә менә “Күнекмә”безгә җибәргән шаян фикерләр ничегрәк икән, күзәтеп алыйк әле.

“Бензины түгел, солысы беткән, тартмый”, – дип аңлатма керткән бу хәлгә Балтач якларында яшәүче Хәкимҗанов Рәшит. Фикер йөреше буенча аны фермада эшләгән тәҗрибәле кеше икәнлеген искәртеп үтү мөһим. **“Машиналарында да, атында да бер “ат” көче дә юк”.** Егәрлек берәмлеге кертелгән күренештә Теләчедән килгән Д. Нуриевның нечкә юморы төсмерләнә. **“Әби аерылып кайткан кызын кабат киявенә илтмәкче – ат каршы”,** – мондый аңлатмага да туры килә бу сурәт. **Рәхмәт, Илгизәр дус, әллә үзеңнең хатыныңны кире китереп куюларын көтеп ятканың булдымы. (Кайсы яктан икәнлегеңне язмагансың, оялгансың, танырлар дип уйлагансыңдыр”. “Ниһаять экологик яктан чиста машина уйлап тапканнар”,** – чын күңеленнән шатлана Чаллыда көн күрүче С. Латыйпов. **“Аерылганда машиналарын икегә бүлгәннәр”,** – дип көлдерә безне Яңа Чабаксардан Д. Саматов. **“Авыл эвакуаторы”,** – монысы Яңа Үзәннән Д. Хәйруллина шаяртуы. **“Берочтан техосмотрга ГАИга һәм мал табибына”,** – дигән кызыклы күзәтүне без ерак Краснодарда яшәп, безне укучы С. Сәлимовтан алдык. **“Ярый әле кредит алмаган идек!”** – шуңа шатланып бетә алмый, үз тормышыннан чыгып, куанып язгандыр мондый күзәтүне казанлы Җ. Гайсин. **“Менә кемнәргә Платон әллә бар, әллә юк!”** – хәзерге вазгыятьне моментында эләктереп алган Алексеевскийда яшәүче Ю. Булатов. “**Кызым, бар төшеп “Чаян”га язылып кил әле, көлкегә калабыз бит язылмыйча, әнә артта “Почта!”** – менә бу шаярту безгә бик ошады. Шул чын ярар иде. Рәхмәт, Балтачтагы “Чаян”чы дустыбыз – Рафис Газизов!

Инде менә бу сюжеттан көлегез! Кызыклы җаваплар көтәбез.





Михаил ЛАРИЧЕВ



Заһир ХӘКИМОВ

Александр КОСМЫЛИН



КӨЛКЕ КАМЕРАСЫ





Александр ЛЕВИТИН

Вячеслав БИБИШЕВ



ГАШЫЙК КАРАК

Билгеле булганча, мәхәббәт хисен даими рәвештә исбатлап торырга кирәк. Күп очракта бүләкләр белән. Ә игътибар билгеләренә акчаң җитмәсә нишләргә?

Казаннан Р. исемле егет бу мәсьәләне үзенчә хәл итәргә булган. Мәгъшукасы белән күрешер алдыннан ул бүләккә дип чәчәк кибетенә керә. Сатучы аңа чәчәк һәм йомшак уенчыклардан җыелма әзерләп бирә. Ромео ни сәбәптер, акча түләргә теләми – кәрзинне эләктереп, урамга чыгып чаба. Кыю сатучы, товарны коткарырга теләп, аны куып китә. Ул гашыйк талаучыдан чәчәкләрне тартып ала, ә 600 сумлык йомшак уенчыклар Р.да кала. Хәзер аны полициядә күпкә күңелсезрәк күрешүләр көтә.

Венера БУЛАТОВА



Ринат АБЗАЛОВ



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Тарих тәгәрмәче безнең юллар өчен түгел бугай.

Дәүләт кешегә йөзе белән борылгач, кеше куркуыннан кычкырып җибәрде.

Караңгылык беткәнче дөнья бетәр кебек.

Сазлык өстендә шәһәр генә түгел, дәүләт тә тора ала.

Бернәрсәдән дә курыкмагыз – бөтен нәрсә дә инде булган.

Эволюция кешене миллионлаган еллар буе турайткан, ләкин бөгелми торган итә алмаган.

Безнең җитешсезлекләребез – яхшы сыйфатларыбызның дәвамы. Менә нигә алар шулкадәр күп.

Ябырылган саен, таплар карала бара.

Халыкның авызын томаласаң, ул фикер иясенә әйләнә.

Вакыт, әлбәттә, иң яхшы табиб. Ләкин ахырда ул да үтерә.

Табигать үзенекен алыр. Өлгерсә, әлбәттә.

Тигезлек математикада гына мөмкин.

Җиде кат үлчә, ә кисәргә урынбасарыңа бир.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды).

Зур ихтирам белән, өлкән дустым Мәгъсүм ГӘРӘЕВкә.

ТӨНГЕ ОЧРАШУ

...Йөрим ялгыз төнге Казан буйлап,
Даһи уйлар керә башыма...
Кинәт күрәм: постаменттан төшеп,
Тукай килә минем каршыма!


– Сәлам, Мәгъсүм!
Сиңа үпкәм бик зур:
Минем хакта сирәк язасың.
Авырмыни кайчак искә алу
Кушлавычның ятим баласын?
Без, шагыйрьләр, синең көнгә калдык –
Бары синнән җегәр алабыз.
...Шунда Тукай, күкрәгемә иңеп,
Сыгып алды бераз балавыз...

– Ярый, Апуш!
Артык өзгәләнмә –
Берәр ничек җаен табарбыз.
Подход табып мөхәррирга керсәк,
Шигырьләрең, бәлки, басарбыз...


...Бәйнә-бәйнә сөйләде ул миңа
Иҗат юлын, яшьлек чакларын.
Ә мин исә ассызыклап үттем
«Кисекбаш»ның слабый якларын...

Таң атканда дустым кулын бирде:
– Ярый, Мәгъсүм! Пока, бигайбә!
Ә теләсәң – сиңа урын җитәр –
Минем белән өскә мен, әйдә!
Табигатьтән тыйнак булсам да мин,
Бу тәкъдимне кире какмадым:
Габдулланы читкә этәрдем дә,
Постаментка таба атладым...

Ринат АБЗАЛОВ



Андрей КЛИМОВ



Валентин ДРУЖИНИН





"СҮНГӘН УЧАК"

Кадерле Чаян! Әле дә хәтеремдә Чаян битләрендә авыл клублары проблемаларына багышланган "Сүнгән учак" дигән рубрика эшләп килә иде. Әлеге рубрика яңарып китсә, бик әйбәт булыр иде. Мисал өчен, авылыбызның мәдәният йортын алыйк. Дөрес, вакытында ачылуын ачыла, ләкин анда керәсе генә килми. Бинага керә торган күренешкә күз салсаң, ни өчен килгәнеңне онытырлык. Таушалган һәм штукатуркасы коелган стенадагы тимер ишек ташландык бер складны хәтерләтә. Әлеге бинаның мәдәният учагы икәнен язып куелган тамгасыннан гына белеп була. Әлеге моңсу күренешкә күз салуга, мәдәният белән кызыксыну тәмам юкка чыга.

Мәдәният йортының мондый хәле беркемне дә борчымый булып чыкты. Әйтүләренә караганда, төзекләндерү эшләрен башкарырга чират җитмәгән. Ярый ла, якын ун ел өчендә бинаның төсен-битен бераз рәтли алсалар. Ансыз яшьләрне дискотекага да кызыктырып булмый бит...

Чистай Выселкасы авылы яшьләре

Чистай районы
ТАТАРСТАН

ЧЫНГА АШМАСЛЫК ШОПИНГ

Хөрмәтле редакция! Ун ел дәвамында "Леруа Мерлен" челтәр кибетен төзү турында сөйләшүләр барды. Берничә тапкыр әлеге төзелешне туктатып, яңадан да башладылар. Тырыша торгач, ниһаять узган ел кибетне ачу бәхетенә дә ирешелде. Чаллылар зур сөенеч кичерде, ник дисәң, төзекләндерү һәм төзелеш өчен бөтен кирәк яракны бер урыннан гына сатып аласы хәзер.

Ләкин кибет янына барып җитү бары тик машиналыларга гына мөмкин булып чыкты. Ә менә җәяүлеләргә бик авырга туры килә. Чөнки трамвай тукталышы бик ерак урнашкан, җәяүлеләр өчен юлны кичү дә трамвай юлын урап узгач кына. Автобуслар бу юлда бөтенләй йөрми. Әгәр дә мәгәр кибеттән күбрәк кирәк-ярак җыйдың икән, такси хезмәтенә мөрәҗәгать итәсе була.

Таксистлар исә, шәһәр вәкилләреннән аермалы буларак, әлеге хәлне тиз үз файдасына хәл итеп, бәяне күтәреп тә куйдылар. Хәзер исә шәһәр халкы гипермаркеттан такси яллап кайтырга мәҗбүр.

Л. ХӘБИБРАХМАНОВ

ЧАЛЛЫ

Госман ГОМӘР “Даһилар мөнбәре” китабына узган гасыр башыннан алып, бүгенгәчә, йөз елдан артык вакыт эчендә яшәп, иҗтимагый, сәяси, икътисадый һәм мәдәни тормышыбызда тирән эз калдырган, үзе яхшы белгән, бергә эшләгән, якыннан аралашкан күренекле кайбер шәхесләрне керткән. Аларның һәрберсе турында тулы бер китап язып булыр иде. Әмма аңа, нишләмәк кирәк, гасыр кешеләренең гадәтләреннән берәр “чеметем” алу белән канәгатьләнергә туры килгән. Шушы “Чеметемнәр” генә дә бөекләрнең кемлеген ачып сала шикелле. Китаптан “Бер капчык нахаллык” дигәнен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез, хөрмәтле укучыларыбыз.

БЕР КАПЧЫК НАХАЛЛЫК

Казан университетында читтән торып кына укый торган журналистика бүлеге ачылу фән дөньясында үзенә күрә бер инкыйлаб иде. Унар ел “производство”да эшләп, азу теш чыгарган шәкертләр җыелдык. Арабызда район, өлкә гәзите хезмәткәрләре, партиянең район, шәһәр һәм өлкә комитеты инструкторлары бар. Бездә “нахаллык” дигәне дә шыплап тутырылган берәр капчык иде.

Хәзерге заман урыс теле буенча лекцияне бик тә чибәр, сабый җанлы, мөлаем йөзле, ифрат инсафлы мөгаллимә Луиза Кәрим кызы Бәйрәмова (әтисе Кәрим абзый икътисадчы галим) укый. Шунда берәүсе кулын күтәрә.

– Слушаю вас, товарищ Салахов!

Дәрестә безгә бары тик шундый мөгамәлә. Нефтьче оператор Әсгать Сәлаховны (хәзер язучы инде) бу әллә ни гаҗәпләндерми. Аның беләсе килә.

– Луиза Кәримовна, а вы замужем?

Менә вәт! Мөгаллимәнең ике бите яна башлый. Әле кияүдә булмаса да, “а как же”, дип, тиз-тиз өстәлен җыештырып, ишеккә юнәлә. Чиктән ашкан “нахаллар” димичә, ни дисең инде?!

Күп лекцияләрне татар теле һәм әдәбияты бүлеге белән бер аудиториядә тыңладык. Ул чакта дәрес алып баручы аспирантлар Флера Сафиуллина, Гомәр Саттаров, Әнвәр Әфләтунов, Вахит Хаков, Тәлгат Галиуллиннар дип әйтмим, хәтта Диләрә Тумашева, Ибраһим Нуруллин, Хатыйп Госман кебек олуг галимнәребезне дә тинтерәтеп бетерә идек. Шөкер, түзделәр, куып чыгармадылар университеттан.

Ә менә безнең “нахаллык”ны икенче бер зур галимебез (ул чакта да мондый зурлауга лаек иде) Якуб ага Агишев ошатты бит, әй! “Мондый нахал группаны беренче тапкыр күрәм”, – дип мактады. Бу шәхес үзе генә дә ни тора! Яше 80 гә җитсә дә, төз гәүдәле, олпат ир иде ул. Ялтыратып кырган башы – аның акыл иясе булуын раслап тора кебек. Күпне белә. Вәкарь белән сөйли. Менә шушы зат безнең күзебезне ачты, дөньяга карашыбызны үзгәртте. Моны ул Тукай иҗаты аша җиткерде. Карасаң-баксаң, теге заманда кайбер галимнәр шагыйрьгә “буржуа” мөһерен тагып, аның әсәрләрен ботарлап бастырганнар икән. Мәсәлән, мәшһүр “Туган тел” шигыренең соңгы ике строфасын китаплардан төшереп калдырганнар.

– Ул нинди строфа? – дип сорыйбыз.

“И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам”.

Авызларыбыз ачык калды. Уйландык. Аңларга тырыштык. Шуларны белер өчен килдек бит без университетка!..

Шагыйрьнең “Китмибез” дигән шигыре белән дә шундый ук хәл килеп чыккан. Анда, урыслар белән лөгать вә әхлак алмашып яшәсәк тә, вакыт-вакыт тукмашып алуыбыз бәян ителгән строфа булган икән. Сызганнар. Халыклар дуслыгына зыян китерә, диптер инде.


Ни аяныч, әле һаман да торгызылмаган шагыйрь сүзләре! Мин моны Габдулла Тукайның 1985 елда нәшер ителгән өч томлыгына карата әйтәм.

Ә Якуб аганың урыны җәннәттә булсын. Безгә дәреслекне җиткергән өчен.



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 14, 1980

– Менә, әз генә тайпылдыңмы, шунда ук – права сорыйлар!



Иван ХАНТЕМИРОВ, «Чаян» № 4, 1974

– Бездә бюрократларны күрмәссез!

Эрнест **ДЫШАЕВ**



ОЗЫН СҮЗНЕҢ КЫСКАСЫ...

Күп белсәң – тиз аерылырсың.

Гади балаларны ләкләк алып килә, ә булачак нәчәлникләрне – секретарь-кош.

Җыештыру ул – чүпне күзгә ташланмый торган урынга күчереп кую.

Сәясәтчеләр, сперматозоидлар кебек – миллионнан берсе генә кеше булып чыга!

Шуышырга туганнар очарга бик яраталар.



Виталий **ФЕОКТИСТОВ**

ЧуАр пресса

БЕР УРЫНДА ЙӨГЕРҮ

Җиңел атлетиканың Халыкара ассоциациясе Россиянең спортсменнары рәтендә допингка каршы көрәшне дәвам итә. Тагын ике йөгерүчене дисквалификацияләгәннәр. Ләкин исемлеккә эләккән Григорий Генералов һәм Алексей Чистов күптәннән исәннәр рәтендә юк. Допинг белән көрәшүчеләрне үзләрен допингка тикшерергә кирәк, күрәсең.

СӘЕР БӘРӘҢГЕ

Ирландия фотографы Кевин Абош танылган кешеләрнең портретларын ясау белән дан казанган. Аның коллекциясендә гап-гади бәрәңге фотосы да бар. Берәү генә дә түгел, хәтта өч экземпляр. Берсе – фотографның шәхси коллекциясендә, икенчесе – Сербия музеенда, ә өченчесен исемсез калырга теләгән эшкуар бер миллион еврога сатып алган. Гәрчә, бу акчага ул берничә эшелон бәрәңге сатып алып, туйганчы фотога төшерә алган булыр иде.


ТӨПТӘ

Поп-арт буенча чит ил осталарыннан үзебезнең инсталляторлар да калышмый. Дизайнер Артемий Лебедев Псков өлкәсенең Дно шәһәренең тимер юл вокзалы каршындагы мәйданга бер сум символы урнаштырган. Моның белән ул рубльнең икътисад төбенә тәгәрәвен мәңгеләштерергә теләгән.





Марк ФРЕДРИКСОН (АКШ)



Генрих БЮТНЕР (Германия)



Эшли ФИНГЕР (Англия)



Курт МЕНГЕ (Австрия)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Кыш. Машинаны җәйгә хәтле саклау катлаулы мәсьәләме? Банктан кредит алып, аны закладка калдырыгыз, ә кредитны депозитка салыгыз. Җәен боларның тәртибен киресенчә эшләгез.

• • •

– Доктор, мин йоклаганда гырлыйм.
– Көчлеме?
– Бик көчле!
– Бу сезнең хатыныгызны борчыймы?
– Юк, мин өйләнмәгән.
– Димәк, сез ялгыз?
– Әйе.
– Шулай булгач, сезнең проблема нәрсәдә соң?
– Мине инде бишенче эш урыныннан кудылар!

• • •

Бер хатын үлчәнергә баскан:
– Һай, мин нинди бәләкәй!
– Сез үзегезне нинди юан дип әйтмәкче буласызмы?
– Юк, бәләкәй дип әйтмәкче булам шул! Стандарт буенча минем авырлыктагы хатын-кыз 20 сантиметрга озынрак булырга тиеш.

• • •

– Мин йөккә уздым.
– Каян шундый фикергә килдең?
– Минем эшемнән күңелем болгана һәм гел тозлы диңгезгә барасым килеп тора!

• • •

– Сезнең тешләрегез бик матур!
– Әнидән шундый алар!
– Шаккаттырлык хәл бит бу... Еш алыштырып киясезме?..

• • •

Фотограф – туйда:
– Каяле безнең бәхетле парларыбыз?
Кунаклардан берәү:
– Әнә ич алар – килен һәм аның әнисе...

• • •

– Кайчан да булса уйга калганың булдымы, ни өчен Незнайка турындагы хикәяләрдә доктор Пилюлькин авыруларны гына түгел, хәтта таза-сау кешеләрне дә дәвалый?
– Юк, ә нигә?
– Чөнки ул түләүле доктор.



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры
һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

16+

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066



МИҢА ӘЛЕ УН ЯШЬ!..

Мин беренче шигыремне 6 нчы сыйныфта укыган чагымда яздым. Безгә кунакка күренекле шагыйрь Нур Гайсин килгән иде. Көне буе ул шигырьләрен укыды. Икенче көнне миңа бер уй килде: туктале, мәйтәм, мин дә Нур абый кебек язып карыйм әле. Менә шуннан бирле туктый алмый язам да язам.

Бу айда миңа 70 тула икән. Ләкин бу мине һич куркытмый. Ни өченме? Бер иптәшемне очраткан идем. Ул ниндидер чит илдә булып кайткан, зиратларын озак карап йөргән. Анда кабер ташларында кайчан туган, кайчан үлгән язылмый икән. Күпме яшәгәне генә язылган, ди. Мәсәлән, 1 яшь, 5 яки 9, 15 яшь йә 20. Ул аптыраган моңа. Сораган:

– Нигә бик әз яшәгәннәр дип? Аңа аңлатып биргәннәр: яшәгән елларда тик пенсиягә чыккач яшәгән еллар гына керә икән! Шулай булгач, миңа 10 гына икән әле! Ничек инде моңа сөенмәскә. Шундый бәләкәй яшемә карамастан, мин иҗат җимешләремне яраткан журналым – “Чаян”ыма даими биреп барам. Менә бүген дә берничә әйберемне укып карагыз әле, хөрмәтле укучыларым.

Ринат МӘННАН

КИҢӘШ

Этләр белән йөргәч халык,
Кайчакта куркасың да...
– Тешләвен беләсең килсә,
Баштан бак... хуҗасына!

УҢАЙ ЯК

Бәяләр коточкыч үсте,
Яңа тормыш башланды:
Әйбер алсаң, сатучылар
“Рәхмәт!” әйтә башлады.

ЗАР

Химиклар ник начар эшли? –
Көннән-көн күңел бизә.
Йөз грамм хәмер эчсәм дә,
Хатыным исен сизә.

ЧЫДАРМЫ?

Анда сыра, монда сыра...
Халык белми чамасын,
Чөмерә дә чөмерә ул.
Акчалары чыдар – кәгазь,
Бавырлары чыдасын!

ХЕЗМӘТ ХАКЫ

Хатын, ачуланма мине,
Вәт, хезмәт хакы айлык:
Эшемә барып җитәрлек
һәм өемә кайтырлык.

СУЛЫШ АЧЫЛУ

Заводыбыз мичләреннән
Элек баксаң, гел төтен
Чыгып тора иде җәен,
Көзен, кышын, яз көнен.
Эшләребез көннән-көнгә
Хәзер уңайга таба:
Завод бөкте – акча бетте.
Сулыйбыз тик саф һава!

ҖЫРЧЫ РӘХМӘТЕ

Мең рәхмәт фән-техникага,
Бурычлымын аңарга:
Минем чебен тавышымны
Яңгырата залларга!

УЗИдан СОҢ УЙЛАНУ

Таш табылды бавырымда,
Табылды бөеремдә...
Каян килгәндер югыйсә
Ташчылар юк нәселемдә,
Ташчылар юк өемдә?



СОРЫЙМЫН


Йөрәгеңне кулларыңа салып
Сузган килеш миңа атладың.
Кабул иттем, чөнки бу дөньяда
Синнән матур кеше тапмадым

Флёра ТАРХАНОВА

Бавырыңны кулларыңа салып
Сузган килеш миңа атладың.
Озак кына карап тордым да мин,
Әйтер сүзләр сиңа тапмадым.
Йөрәгеңне узган елда суздың,
Ярты елдан булды бөерләр...
Уйлап кына кара, матур кешем,
һәр әгъза да кирәк бит, диләр.
Алга табаниләр сузарсың син?!
Куркып торам инде, йокы юк...
Әйе, әйе, хәзер барысы булыр,
Тик шуны мин сорыймын – төшмә
Кендектән дә аска син берүк.

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Олыгайган саен хатын-кызлар нигә юаная?

2. "Кара" сүзенең ничә мәгънәсе бар?

3. Түләүле табиб белән бушка эшләүче табиб арасындагы аерма?

4. Рәнҗетмичә генә әйткәндә, өйләнгән кешене ничек дип атарга була?

5. Ни өчен безнең түрәләр үзләренең балаларын чит илдә укыталар, акчаларын шунда саклыйлар, күчемсез милек сатып алалар, ә үзләре анда яшәмиләр?

6. Кеше нинди ике төргә бүленә?

7. Мона Лиза нигә бик серле елмая?

ҖАВАПЛАР

1. Чөнки тәҗрибә, зирәклек һәм белем баш миенә генә сыеп бетми, алар бөтен гәүдәгә тарала. 2. Төс, бак (смотри), язу сыекчасы (чернила). 3. Акча таләп итмичә эшләүче табибка син үзеңнең авыру икәнлегеңне исбат итә алмыйсың, ә түләүлесенә – сәламәт икәнлегеңне! 4. Мөмкинлеге чикләнгән ир кеше. 5. Чөнки анда безнең гадел хөкем органнары юк. 6. Җәнлекләрне сакларга кирәк диючеләргә һәм тешләнгәннәргә. 7. Иренең яшергән әйберен тапканга күрә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемнәрен укыгыз. Журналыбызның 2 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«КОНДЫРАК БОЛЫННАРЫ», «ДУЛКЫН».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Яңа Кишет авылыннан **Рамил ЙОСЫПОВ!**



Карикатура осталары

Пётр КОЗИЧ (Белоруссия)





Рәссам Пётр КОЗИЧ Витебск шәһәрендә яши һәм эшли. Аның карикатуралары «Вожык» белорус юмористик журналының «кендеге» булып тора. Бүген укучыларыбызны каләмдәшебезнең иҗаты белән таныштырабыз.









